ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2023 г. Казань № 552-48/кс-2023

«Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (химик чистартылган) һәм агынты суларны (механик) чистартуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2021 №415-103/кс-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 елга төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, техник суга (химик чистартылган суга), агынты суларны (механик суларны) чистартуга 2024-2026 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемено төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2023 №57-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен техник суга (химик чистартылган суга), агынты суларны (механик суларны) чистартуга 2022-2026 елларга тарифлар билгеләү турында» 01.12.2021 №415-103/кс-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 №614-189/кс-2022 карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ иркле файдаланылырга тиешле

мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2023 № 552-48/кс-2023 карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ өчен техник (химик чистартылган) суга һәм агып җыела торган (механик) суларны чистартуга 2022-2026 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Техник суга тариф (химик чистартылган), (бер ставкалы), сум/куб. м | Агынты суларны (механик) чистартуга тариф (бер ставкалы), сум/куб. м |
|---|---|---|---|---|
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 50,52 | 4,55 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 69,54 | 7,71 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 70,42* | 7,47* |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 70,42 | 7,47 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 122,16 | 15,04 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 81,50 | 10,23 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 81,50 | 10,23 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 81,50 | 10,23 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 102,49 | 11,77 |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 №614-189/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге